КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 5 февраль г.Казань № 58

Татарстан Республикасы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын планлаштыру һәм үткәрү буенча эшне оештыру турында нигезләмәне раслау хакында

«Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән халыкны һәм территорияләрне саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын һәм эвакуация органнар эшчәнлеген камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын планлаштыру һәм үткәрү буенча эшне оештыру турында нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары җитәкчеләренә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килгән очракта әлеге карар белән расланган Нигезләмә нигезендә чаралар планлаштырырга.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килгән очракта әлеге карар белән расланган Нигезләмә нигезендә чаралар планлаштырырга тәкъдим итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфасын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин